РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«15» июнь 2020 ел Олы Кайбыч ав. № 235

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда федераль бюджетны үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 1 апрелендәге 103-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 22 апрелендәге 120-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 23 сентябрендәге 182 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә (2020 елның 27 февралендәге 3 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

15.11 статьяның 4 пунктындагы «һәм башкарыла» сүзләрен төшереп калдырырга;

15.11 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукын күздә тотмый торган муниципаль гарантия бары тик хуҗалык җәмгыятенең, акцияләренең 100 проценты (өлешләре) тиешле гавами-хокукый берәмлек (гарант), муниципаль унитар предприятие, аның мөлкәте тиешле гавами-хокукый берәмлек (гарант) милкендә булган, ә принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын күздә тотмый торган Россия Федерациясе дәүләт гарантиясе белән генә тәэмин ителергә мөмкин, шулай ук Россия Федерациясе тарафыннан гамәлгә куелган (төзелгән) дәүләт корпорациясе яисә дәүләт компаниясе йөкләмәләре дә тәэмин ителергә

мөмкин.»;

15.11 статьяның 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Кредит (заем, шул исәптән облигация) буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итә торган муниципаль гарантия муниципаль гарантиядә күрсәтелгән төп йөкләмәләр шартлары муниципаль гарантиядә күрсәтелгән гарантның алдан язмача ризалыгыннан башка үзгәртелмәгән очракта гына һәм (яисә) кредит (заем, шул исәптән облигация) белән тәэмин ителгән муниципаль гарантия акчаларыннан максатчан файдаланмаган очракта, кредит шартнамәсе һәм кредит буенча муниципаль гарантия бирү турындагы шартнамә нигезендә кредитны максатчан куллануны тикшереп тору башкарыла торган кредит чараларыннан (заем, шул исәптән облигация) файдаланган очракта гына гарант тарафыннан чакыртып алынырга тиеш.»;

15.11 статьяның 16 пунктындагы 5 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

15.6 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль гарантия муниципаль гарантия белән тәэмин ителә торган йөкләмәләр күрсәтелгән валютада бирелә.»;

1. 2021 елның 1 гыйнварына кадәр 10 статьяның 2 пунктының, 37 статьяның 3 пунктының, 34 статьяның 1 абзацының гамәлдә булуын туктатып торырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе А.И.Рәхмәтуллин